ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

10.07.2017 г. Казань № 086-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләргә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләре гомуми кулланылыштагы мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкин булган белешмәләр урнаштыра алырлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлар битләре адреслары турындагы белешмәләрне кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 20.2 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 17.2 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләргә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләре гомуми кулланылыштагы мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкин булган белешмәләр урнаштыра алырлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлар битләре адреслары турындагы белешмәләрне кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитеты Рәисенең
10.07.2016 № 086-од
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләргә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләре гомуми кулланылыштагы мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкин булган белешмәләр урнаштыра алырлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлар битләре адреслары турындагы белешмәләрне кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү

ТӘРТИБЕ

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләргә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләре гомуми кулланылыштагы мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкин булган белешмәләр урнаштыра алырлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлар битләре адреслары турындагы белешмәләрне кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе (алга таба – Тәртип) түбәндәгеләрне билгели:

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләргә дәгъва кылучы гражданнар (алга таба – граждан) һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәре) тарафыннан гомуми кулланылыштагы мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкин булган белешмәләр урнаштыра алырлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлар битләре адреслары турындагы белешмәләрне (алга таба – Сайтлар турында белешмәләр, «Интернет» челтәре) бирү кагыйдәләрен;

Сайтлар турындагы белешмәләрне кабул итү һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибен.

2. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге № 149-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы

1 өлеше нигезендә гомуми кулланылыштагы мәгълүмат дигәндә алу мөмкинлеге чикләнмәгән һәркемгә мәгълүм булган белешмәләр һәм бүтән мәгълүмат аңлашыла. Бу чакта мәгълүмат алу мөмкинлеген чикләүләр булмау даирәсе чикләнмәгән затларның урнаштырылган мәгълүматны каршылыксыз алуы һәм аны граждан хезмәткәре яисә граждан ризалыгыннан башка үзе теләгәнчә куллану мөмкинлеген күз алдында тота.

3. Граждан хезмәткәренең һәм гражданның шәхесен идентификацияләргә ярдәм итүче белешмәләр сыйфатында түбәндәге белешмәләрнең җыелмасы яисә берсе булырга мөмкин: фамилиясе һәм исеме, фотографиясе, хезмәт урыны.

## II. Сайтлар турындагы белешмәләрне кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турындагы белешмәләр түбәндәгеләрне күз алдында тота:

граждан – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) кергәндә граждан хезмәтенә керү елы алдыннан килүче өч календарь ел эчендә;

граждан хезмәткәре – ел саен, хисап елыннан килүче елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, үткән календарь ел өчен.

5. Сайтлар турындагы белешмәләр гражданнар һәм граждан хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форма (алга таба – Форма) буенча тапшырыла.

6. Гомуми кулланылыштагы мәгълүмат, әгәр ул граждан хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштырылган булса, Формада чагылмаска тиеш.

7. Тутырылган Форма граждан хезмәткәре яисә граждан тарафыннан Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетыныж Сайтлар турындагы белешмәләрне эшкәртү өчен Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Рәисе боерыгы белән җаваплы итеп билгеләнгән хокукый һәм кадрлар эше бүлеге хезмәткәренә (алга таба – Җаваплы зат) тапшырыла.

8. Җаваплы зат Форманы тутыру тулылыгын, анда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен файдаланып күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя, белешмәләрне алган көннендә үк әлеге Тәртип кушымтасы нигезендәге форма буенча журналга кертә.

9. Тутырылмаган юллары булган Форма кабул ителмәскә тиеш.

10. Граждан тапшырган Формада дөрес булмаган белешмәләр ачылган очракта, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куюдан баш тартылу турында кичекмәстән аңа хәбәр итә.

11. Сайтлар турындагы белешмәләр Җаваплы зат тарафыннан граждан хезмәткәрләренең «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси карточкаларына кертелә.

12. Граждан хезмәткәрләре һәм гражданнар тарафыннан тапшырылган Формалар кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегендә биш ел буена саклана, шуннан соң

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы Персональ белешмәләрне эшкәртү кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә юк ителергә тиеш.

## III. Сайтлар турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Сайтлар турында граждан хезмәткәрләре тапшырган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Рәисе (рәис вазыйфаларын үтәүче зат) (алга таба – Рәис) боерыгы буенча гамәлгә ашырыла.

14. Түбәндәгеләр тарафыннан язма рәвештә тапшырылган җитәрлек мәгълүмат тикшерү өчен нигез була:

хокук саклау органнары, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан;

сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкче органнары һәм сәяси партияләр булмаган, закон нигезендә теркәлгән бүтән гомумроссия, төбәкара һәм төбәк җәмәгать берләшмәләре тарафыннан;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы тарафыннан;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан.

15. Җаваплы зат граждан хезмәткәренә аңа карата тикшерү башлану турында тикшерү уздыру турында боерык бастырып чыгарылган көннән соң ике эш көне эчендә язма рәвештә хәбәр итә.

16. Сайтлар турында граждан хезмәткәре тапшырган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Җаваплы зат тарафыннан аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырган гомуми кулланылыштагы мәгълүматны эзләү һәм әлеге мәгълүматның электрон күчермәләрен (скриншотларын) булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

17. Граждан хезмәткәре тикшерү барышында һәм аның нәтиҗәләре буенча язма рәвештә аңлатмалар бирергә, өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

18. Әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына кушып куела.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында җыелган мәгълүмат Рәискә тикшерү уздыру турында боерык басылып чыккан көннән 10 эш көненнән дә артмаган срокта тапшырыла.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көнлек срокта Рәис түбәндәге караларның берсен кабул итә:

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чаралары күрү өчен нигезләр булмау турында;

граждан хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чаралары күрү турында;

хокук бозулар, җинаять, экстремистик эшчәнлектә катнашуы билгеләре булганда, тикшерү материалларын аларның компетенцияләре нигезендә дәүләт органнарына җибәрү турында.

21. Җаваплы зат Рәисенең карар кабул итүе турында үзенә карата тикшерү уздырылган граждан хезмәткәренә язма рәвештә ике эш көне эчендә хәбәр итә.

22. Сайтлар турындагы белешмәләр Рәиснең язма ризалыгы белән, бер үк вакытта бу хакта үзенә карата тикшерү уздырылган граждан хезмәткәренә хәбәр итеп, хокук саклау органнарына, сәяси партияләрнең даими эшләүче җитәкче органнарына һәм сәяси партияләр булмаган, закон нигезендә теркәлгән бүтән гомумроссия, төбәкара һәм төбәк җәмәгать берләшмәләренә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, персональ белешмәләр һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын үтәгән килеш, тикшерү өчен нигез булган мәгълүмат биргән гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрелергә мөмкин.

23. Тикшерү материаллары тикшерү тәмамланганнан соң өч ел эчендә Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторында саклана һәм шуннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турындагы белешмәләрне тапшыру өчен җаваплылык

24. Граждан Сайтлар турындагы белешмәләрне тапшырмаган очракта, граждан хезмәтенә алынмый, ә граждан хезмәткәре исә граждан хезмәтендә була алмый.

25. Граждан хезмәткәренең Сайтлар турындагы белешмәләрне тапшырмавы граждан хезмәтеннән чыгаруга китерерлек хокук бозу була.

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләргә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан гомуми кулланылыштагы мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкин булган белешмәләр урнаштыра алырлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яисә) сайтлар битләре адреслары турында тапшырылган белешмәләрне исәпкә алу

ЖУРНАЛЫ

| № т/с | **Форманы тапшыру/ кабул итү датасы** | **Форманы тапшыру-чы зат Ф.Ис.Ат. ис.** | **Форманы тапшыручы зат вазыйфасы (граждан дәгъва кылучы вазыйфа)** | **Форманы тапшыручы зат имзасы (яисә почта аша кергәндә Форманың керү номеры)** | **Форманы кабул итүче затның Ф.Ис. Ат. ис.** | **Форманы кабул итүче затның имзасы** | **Тикшерү турында мәгълүмат (боерык реквизит-лары, тикшерү нәтиҗәсе)** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |